# Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк авылы халык җыены

**2021 нче елның 17 нче декабрендәге 2 нче номерлы КАРАРЫ**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Сәйтәк авылы гражданнарының җыены

карар итте:

1. 2022 елда Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк авылы территориясенддә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән үзара салым акчаларын 300 сум күләмендә, ә I һәм II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларга бер тапкыр түләүне киметеп 150 сум күләмендә кертергә.
2. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1. су астына төшүче су насосы сатып алу.
2. кышкы чорда юлларны кардан чистарту.
3. Урамнарны яктырту

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Сәйтәк авылының мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында "Бәзәкә авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга www.mendeleevsk.tatar.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Бәзәкә авылҗирлегебашлыгы И.И. Кашафетдинов